КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 3 апрель г.Казань № 261

Татарстан Республикасында гражданнарны гемофилия, муковисцидоз, гипофизар нанизм, Гоше авыруы, лимфоидлы, кан ясагыч һәм аларга охшаш тукмаларның яман шешләре, таркау склероз, гемолитик-уремик синдром, системалы башлану белән яшүсмерләр артриты, I, II һәм VI типтагы мукополисахаридоз белән авыручыларны дәвалау өчен күздә тотылган, шулай ук органнарны һәм (яки) тукымаларны трансплантацияләгәннән соң дару чаралары белән тәэмин итү буенча оештыру чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Затларны лимфоидлы, кан ясагыч һәм аларга охшаш тукмаларның яман шешләре, гемофилия, муковисцидоз, гипофизар нанизм, Гоше авыруы, таркау склероз, гемолитик-уремик синдром, системалы башлану белән яшүсмерләр артриты, I, II һәм VI типтагы мукополисахаридоз белән авыручыларны дәвалау өчен күздә тотылган, шулай ук органнарны һәм (яки) тукымаларны трансплантацияләгәннән соң дару чаралары белән тәэмин итү буенча оештыру чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына һәм Байконур шәһәре бюджетына башка бюджетара трансфетлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 ел, 30 декабрь, 1753 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында гражданнарны гемофилия, муковисцидоз, гипофизар нанизм, Гоше авыруы, лимфоидлы, кан ясагыч һәм аларга охшаш тукмаларның яман шешләре, таркау склероз, гемолитик-уремик синдром, системалы башлану белән яшүсмерләр артриты, I, II һәм VI типтагы мукополисахаридоз белән авыручыларны дәвалау өчен күздә тотылган, шулай ук органнарны һәм (яки) тукымаларны трансплантацияләгәннән соң дару чаралары белән тәэмин итү буенча оештыру чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип санарга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2010 елда Татарстан Республикасында гражданнарны лимфоидлы, кан ясагыч һәм аларга охшаш тукмаларның яман шешләре, гемофилия, муковисцидоз, гипофизар нанизм, Гоше авыруы, таркау склероз белән авыручыларны дәвалау өчен күздә тотылган, шулай ук органнарны һәм (яки) тукымаларны трансплантацияләгәннән соң дару чаралары белән тәэмин итү буенча оештыру чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында» 2010 ел, 31 декабрь, 1185 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2011 елга, 2012 һәм 2013 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2010 ел, 27 декабрь, 1122 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 21 декабрь, 1047 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2010 елда Татарстан Республикасында гражданнарны лимфоидлы, кан ясагыч һәм аларга охшаш тукмаларның яман шешләре, гемофилия, муковисцидоз, гипофизар нанизм, Гоше авыруы, таркау склероз белән авыручыларны дәвалау өчен күздә тотылган, шулай ук органнарны һәм (яки) тукымаларны трансплантацияләгәннән соң дару чаралары белән тәэмин итү буенча оештыру чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында» 2010 ел, 31 декабрь, 1185 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 20 гыйнвар, 19 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2011 елга, 2012 һәм 2013 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2010 ел, 27 декабрь, 1122 нче карарының 5 нче пунктындагы егерме дүртенче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2012 елга, 2013 һәм 2014 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2011 ел, 5 декабрь, 994 нче карарының 5 нче пунктындагы егерменче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2012 ел, 11 декабрь, 1078 нче карарның 5 нче пунктындагы унҗиденче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан

Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2013 ел, 10 декабрь, 964 нче карарның 5 нче пунктындагы унбишенче абзацы.

3. Бу карарның гамәле 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 3 апрель, 261 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасында гражданнарны гемофилия, муковисцидоз, гипофизар нанизм, Гоше авыруы, лимфоидлы, кан ясагыч һәм аларга охшаш тукмаларның яман шешләре, таркау склероз, гемолитик-уремик синдром, системалы башлану белән яшүсмерләр артриты, I, II һәм VI типтагы мукополисахаридоз белән авыручыларны дәвалау өчен күздә тотылган, шулай ук органнарны һәм (яки) тукымаларны трансплантацияләгәннән соң дару чаралары белән тәэмин итү буенча оештыру чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану

**ТӘРТИБЕ**

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасында гражданнарны гемофилия, муковисцидоз, гипофизар нанизм, Гоше авыруы, лимфоидлы, кан ясагыч һәм аларга охшаш тукмаларның яман шешләре, таркау склероз, гемолитик-уремик синдром, системалы башлану белән яшүсмерләр артриты, I, II һәм VI типтагы мукополисахаридоз белән авыручыларны дәвалау өчен күздә тотылган, шулай ук органнарны һәм (яки) тукымаларны трансплантацияләгәннән соң дару чаралары белән тәэмин итү буенча оештыру чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчадан (алга таба – акча) файдалану механизмын билгели.

2. Акчалар дару препаратларын саклауга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын финанс белән тәэмин итү, дару препаратларын даруханә оешмаларына җиткерү, шулай ук Татарстан Республикасы чикләрендә дару препаратларын исәпкә алуның һәм хәрәкәт итүнең электрон мәгълүмат базасын булдыру һәм алып бару максатларында бирелә.

3. Акчаларны тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләме чикләрендә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан финанслауның иң чик күләмнәрен җиткергәннән соң расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җиткерәчәк.

5. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы:

дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия

Федерациясе законнары нигезендә дару препаратларын даруханә оешмаларына җиткерү, шулай ук әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы чикләрендә дару препаратларын исәпкә алу һәм хәрәкәт итү белешмәләренең электрон базасын булдыру һәм алып бару өчен дәүләт контрактларын (шартнамәләрне) төзи;

дару препаратларын саклауга, дару препаратларын аптека оешмаларына китерүгә дәүләт контрактлары (шартнамәләре) төзелгән оешмаларга, шулай ук Татарстан Республикасы чикләрендә дару препаратларын исәпкә алу һәм хәрәкәт итү белешмәләрнең электрон базасын булдыруга һәм алып баруга, дәүләт контрактлары (шартнамәләр) шартларына туры китереп, акча күчерә.

6. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына түбәндәгеләрне тапшыра:

ел саен, акча бирү елына кадәрге елның 25 декабреннән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган форма буенча аларны бирү шартларын үтәү турында хисап;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча хисап.

7. Акчаларны максатсыз файдалану Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка китерә.

8. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмый калган акчалар Россия Федерациясенең бюджет законнары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.